

ISSN 0868-4545



Борын-борын заманда...

Кадерле дускай!

Белеп-сизеп торабыз: син әкиятләр укырга, әгәр инде үзең әле укый белмәсәң, аларны әти-әниеңнән, әби-бабаңнан яисә абый-апаңнан укыттырырга-сөйләттерергә яратасың. Рәссам абыйларның һәм апаларның ул әкиятләргә ясаган матур-матур сурәтләре дә синең игътибарыңнан читтә калмый.

Маҗаралы, кызыклы әкиятләр дә, кошлар һәм хайваннар турындагы әкиятләр дә, кыскасы, барча-барча әкиятләр дә синең күңелеңне җәлеп итәдер дип уйлыйбыз.

Журналның ошбу саны да тулысынча диярлек әкиятләрдән тора.

Укы, сөен, уйлан, әкиятләрдән гыйбрәт ал.

Кем белә, бәлки син дә әкиятче булырсың. Абдулла Алиш, Батулла, Фәнис Яруллин, Роза Хафизова кебек бик күп әкиятче язучыларыбыз, шагыйрьләребез дә кайчандыр синең кебек сабый булганнар бит!

Йә, дускай, укы, тыңла:

Борын-борын заманда,
Борын озын заманда,
Барлык озынборынның
Булган озын борыны.
Озын булгач борыннар,
Барлык озынборыннар,
Борын белән борылып,
Борын белән орынып,
Очып йөргән һавада
Борын-борын заманда...



© "Салават күпере", 1998 ел

Ләбиб ЛЕРОН

Әкияти башламнар

Әле син тумаганда...

Әле мин булмаганда,
Әле син тумаганда,
Озынколак куяннар
Качышлы уйнаганнар.
Әбәкле уйнаганнар,
Чәбәкле уйнаганнар...
Көнозын уйнаганнар –
Уйнап һич туймаганнар!
Әтәчтән дә иртәрәк
Йокыдан торган алар.
Шуңадырмы барсы да
Бик матур булган алар.
Шуңадырмы барсы да
Бик батыр булган алар!



Кичә-кичә заманда...

Кичә-кичә заманда,
Бүген-бүген заманда
Һәм иртәгә заманда,
Һәм берсекөн заманда
Яшәгән, ди, яшәгән...
Тукта, кем соң яшәгән?
Әйтмим, үзең бел әле;
Һәм энеңә-сеңлеңә
Әкият итеп сөйләле...

Авыз итегез...

Мин белгәннәр, белмәгәннәр,
Дус-ишләр яки ятлар!
Авыз итегез – сезгә бу:
Бер кесә әкиятләр.

Әтәч белән песи

Татар халык әкияте

Әтәч белән песи бервакытны урманга барганнар, чикләвек җыярга. Урманда әтәч агач башына менгән дә чикләвекләрне ыргытырга тотынган, ялгыш песинең күзенә эләктергән. Песи милициягә жалуга киткән. Китергән милицияне. Милиция әйткән песигә:

– Әтәч, ник син песинең күзенә чикләвек ыргыттың?

Әтәч әйткән:

– Ә нигә чикләвек агачы минем ыштанымны ертты? Шуңа ачуым килеп ыргыткан идем.

Милиция чикләвек агачын чакырткан:

– Чикләвек агачы, син ник әтәчнең ыштанын ерттың?

Чикләвек агачы әйтә:

– Ә ник кәҗә минем кайрымны кимерә? Шуңа ачуым килеп ерттым мин аның ыштанын.

Милиция әйтә:

– Барыгыз, кәҗәне китерегез!

Кәҗәне китерәләр дә сорыйлар:

– Нигә син чикләвек агачының кайрысын кимерәсең?

Кәҗә әйтә:

– Мине бит көтүче карамый.

Көтүчене китерәләр:

– Көтүче, син ник кәҗәне сакламыйсың?

Көтүче әйтә:

– Хуҗа аның өчен миңа акча бирми, шуның өчен сакламыйм.

Хуҗаны милициягә чакырталар:

– Син ник кәҗәне саклаган өчен акча бирмисең?

Хуҗа әйткән:

– Ник минем бакчаларымны дуңгызлар сөреп бетерә?

Дуңгызны да милициягә чакыралар:

– Дуңгыз, син ник хуҗаңның бакчасын казып-сөреп йөрисең?

Дуңгыз әйтә:

– Ә ни өчен минем бала-чагаларымны бүре ашады?

Хәзер инде бүрене эзләтергә җибәрәләр. Эзлиләр, эзлиләр, әле дә булса таба алмыйлар, ди, бүрене.

(Р.Ягъфәров төзеп чыгарган "Балалар фольклоры" китабыннан алынды.)

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Алдакчы туганнар

Португал халык әкияте

Яшәгән, ди, ике туган – ике агай-эне. Бер мәл алар шулхәтле хәерчеләнгәннәр, акчаны кайдан, ничек табарга да белмәгәннәр. Ниһаять, уйлана торгач, өлкән туганның башына шундый фикер килгән:

– Менә нәрсә, энекәем, әйдә без дөнья гизәргә чыгып китик тә алдап-йолдап акча эшлик. Беребез ялганлап алдан, икенчебез аның алдавын раслап арттан барыр...

Шулай итәргә булганнар, ди, болар.

Өлкән туган бер авылга килеп керүгә тотынган кычкырырга, тотынган кычкырырга... Кеше ышанмастай яңалык беләм, ди икән, акча бирсәгез генә ул яңалыкны әйтәм, ди икән.

Халык җыелган. Ялганчы туган сөйли башлаган:

– Шундый-шундый бер авылда җиде куллы бала яши, – ди икән.

Кешеләрнең шаккатудан авызлары шардай ачылган, ди. Алар шундый гаҗәеп яңалык әйткәне өчен егеткә акча биргәннәр. Ә егет исә тизрәк таю ягын караган. Бу авылда әлеге хәбәргә ышанмаучылар да табылган. Алар таныш түгел егетнең әйткәне дөресме-түгелме икәнен белү өчен сәер бала туган авылга барырга җыенганнар. Шулвакыт болар каршына өлкән туганның энекәше килеп чыккан. Мин нәкъ менә шул яктан киләм, – дигән ул.

Кешеләр аннан:

– Син фәлән авылда җиде куллы бала күрмәдеңме? – дип сораганнар.

– Андый баланы күрүен күрмәдем, – дигән егет, – әмма кер бавына эленгән җиде җиңле күлмәкләр күрдем.

– Димәк, хәбәр дөрес булып чыкты, – дигән нәтиҗәгә килгәннәр кешеләр һәм бу алдакчы егеткә дә акча биргәннәр.

Бу вакытта өлкән туган икенче авылга барып җитеп, юлында очраган һәр кешегә чираттагы ялганын сөйләгән.

– Фәлән-фәлән исемле бер адәм киң ябалдашлы нарат очына тегермән салган. Үз күзләрем белән күрдем – исләрең китәрлек! – ди икән.

Шуннан соң ул кесә тутырып акча җыйган да тизрәк авылдан ычкыну ягын караган.

Кешеләр әлеге хәбәргә ышаныргамы-ышанмаскамы дип кенә торганда, өлкән туганның энекәше болар каршында ялт пәйда булган.

– Юлчы туган, нарат башына салынган тегермән күрергә туры килмәдеме? – дип сораганнар аннан кешеләр.

– Дөресен генә әйткәндә, миңа нарат буйлап төшеп килүче бер егетне генә күрергә туры килде. Аның җилкәсендә ике капчык он бар иде, – дип җавап биргән егет.

– Димәк, хак икән, – дип шатланышканнар кешеләр һәм егеткә байтак кына акча биргәннәр.

Шуннан соң егет тизрәк абыйсын куып җитәргә һәм яңадан-яңа "әкиятләр" уйлап чыгарырга дип янә юлын дәвам иткән, ди.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Хәйләкәр чегән малае

Чегән халык әкияте

Әниләре балаларын чакырып алган да:

– Кемгә аш салып бирим? – дип сораган.

– Миңа! – дип кычкырып җибәргән өлкән улы. – Миңа күбрәк сал! Бик ашыйсым килде.

Балалар чөгендер шулпасын ялт иттереп куйганнар.

Шуннан әниләре алардан:

– Кемгә ботка бирим? – дип сораган.

– Миңа, миңа ботка! – дип янә кычкыра башлаган өлкән улы. – Күбрәк сал, әни, яме!

Балалар ботканы да сыптырып куйганнар. Инде әниләре сорый икән:

– Йә, кайсыгыз ат котәргә бара?

– Без, без! – дип кычкырышалар балалары, абыйлары исә дәшми тора икән.

– Ә син ник дәшмисең, улым? – дип сораган өлкән улыннан әнисе. – Ашаганда барысыннан да күбрәк ашадың, эшкә дигәндә, авызыңа су капкандай торасың.

– И, әни, – дип үпкәләп җавап биргән өлкән улы. – Мин ике эшеңне дә башкаларга караганда күбрәк эшләдем, инде өченчесен дә миңа кушарсыңмы тагын?

(М. Шабаев тәрҗемәсендә дөнья күргән "Чегән әкиятләре" дигән китаптан (1992) алынды.)



Рәссам Юлия ЩЕТИНКИНА

Сөйлимме яңабаштан?

Киеп алдым эшләпә ...

Алдавыч әкиятләр

Борын-борын заманда,
Киеп алдым эшләпә,
Киеп алгач эшләпә,
Чыгып йөгердем шул шәпкә.
Очрады миңа бәбкә.
Аннан шундый курыктым,
Куркуымнан егылдым.
Бераздан тордым сикереп,
Бәбкә тора кикереп.
Барамын урам буйлап,
"Өй салам!" – диеп уйлап.
Аны салырмын таштан...
Тукта!
Сөйлимме яңабаштан?



Мич башындагы кое

Әүвәл заманда булган, ди,
Бер карт белән бер карчык.
Аларга кое бик ерак булган, ди.
Алар уйлаганнар
Мич башында кое казырга.
Иңдергәннәр, ди, таш өстенә таштан...
Сөйлимме яңабаштан?



Рәссам Светлана ПРИВИНА





Ганс Христиан ***АНДЕРСЕН,***
Дания язучысы.

Принцесса һәм борчак

Яшәгән бер принц. Ул принцессага өйләнергә уйлаган, әмма андый-мондыена гына түгел, чын-чынлап принцесса булганына. Шундыйны эзләп принц бөтен дөньяны әйләнеп чыккан. Ләкин үзенә лаеклысын эзләп табалмаган. Принцессалар бик күп очраган аңа, тик аларның чын-чынлап принцесса булуларын гына берничек тә ачыклый алмаган ул.

Шулай бервакыт кичен бик яман көчле давыл чыккан: яшен яшьнәгән, күк күкрәгән, яңгыр чиләкләп койган – котларың очарлык булган! Шунда кинәт шәһәр капкасын шакыганнар. Карт король капканы ачарга киткән.

Капка төбендә бер принцесса басып тора икән. "Мин чынлап та чып-чын принцесса", – дигән ул.

"Ярар, без моны ачыкларбыз!" – дип уйлаган королева һәм сарайдагы йокы бүлмәсенә кергән дә, караваттан түшәкләрне алып, ятакка бер борчак куйган. Шуннан соң егерме түшәк китереп җәйгән. Аннары алар өстенә диңгез үрдәге йонынннан хәстәрләнгән янә егерме ястык салган.

Менә шул урын өстендә йокларга яткан инде принцесса.

Иртән аннан ничек йоклавы белән кызыксынганнар.

– Аһ, коточкыч! – дигән принцесса. – Төне буе йоклый алмадым. Мин ниндидер каты әйбер өстендә яттым. Бөтен тәнем күгәреп-зәңгәрләнеп бетте. Хәлкәйләрем шулхәтле начар!

Шулчакта һәммәсе дә каршыларында чыннан да чып-чын принцесса басып торуын аңлаганнар. Егерме түшәк һәм диңгез үрдәге йонынннан әзерләнгән егерме ястык астында булган борчакның барлыгын сиземләгән бит ул. Бары тик чын принцесса гына шулай иркә булып үсә ала.

Шуннан соң принц ошбу принцессага өйләнгән. Ә борчакны исә сирәк әйберләр саклана торган музейга куйганнар. Аны әле хәзер дә шунда күрергә мөмкин. Дөрес, берәрсе алай-болай урламаган булса. Ышаныгыз, мин сезгә чын вакыйга сөйләдем!

Рәссам Светлана ИБРАГИМОВА





Джанни РОДАРИ,
итальян язучысы.

Сәяхәтче маймыллар

Бервакыт зоопаркта яшәүче маймыллар дөнья буйлап сәяхәт итәргә булдылар.

Менә алар бардылар, бардылар... Бара торгач, ардылар. Шулчак арадан берәве сорап куйды:

– Йә, илгизәр дускайлар, нәрсәләр күрәбез инде без хәзер?

– Арслан читлеген, бассейндагы моржларны һәм жираф өен, – дип җавап бирде икенче маймыл.

– Дөнья нинди зур да соң! – дигән бердәм фикергә килделәр маймыллар.

Һәм янә юлларын дәвам иттеләр. Бардылар, бардылар... Ниһаять, төш вакыты җиткәндә ял итәргә туктадылар.

– Ә хәзер нәрсәләр күрәбез инде?

– Жираф өен, бассейндагы моржларны һәм читлектәге арсланны!

– Бигрәк сәер инде бу дөнья! Әмма сәяхәт итүе барыбер күңелле!

Алар тагын юлга кузгалдылар һәм кояш баер алдыннан гына сәяхәт итүдән туктадылар.

– Йә, хәзерниләр күрәбез?

– Арслан читлеген, бассейндагы моржларны һәм жираф өен.

– Дөнья бигрәкләр дә кызыксыз инде! Эч пошыргыч, күңелсез! Һаман бер үк нәрсәләр. Үзгә төрле бер ни дә юк! Болай сәяхәт итү сәяхәт итүмени! – диештеләр маймыллар.

Әлбәттә, нинди сәяхәт булсын бу! Хәер, маймыллар үзләренчә сәяхәт иттеләр итүен, ләкин читлектән чыкмыйча гына.

Карусельдәге атлар шикелле бер урында әйләнделәр дә әйләнделәр – аларның дөнья гизүләре шул булды.



Рәссам Сергей АНДРИАНОВ



Расс

Ләбиб ЛЕРОН

Сәер өй һәм тәмле-тәмле тычканнар

Бер авылда бик тә сәер өй бар иде. Сәерлеге шунда: өйнең нигезләре ап-ак шикәрдән, бүрәнәләре сап-сары балдан, идән-түшәмнәре сары майдан, миче ап-ак сырдан, морҗасы туңдырмадан, түбәсе печинҗәдән иде.

Бу өй турында Чичитүш һәм Чичиҗан дигән ике тычкан белеп алды. Белүгә, өй янына мыштыр-кыштыр йөгереп килеп тә җиттеләр. Килеп тә җиттеләр, өй базына төшеп тә киттеләр. Башта алар баздагы каймак-катык ише сый-нигъмәтләрне ашап бетерделәр, аннары нигезне яларга, кимерергә тотындылар. Нигез беткәч, бүрәнәләрне дә ашап киттеләр. Мич белән морҗаны тиз генә юк иткәч, түбәне кимерергә керештеләр. Түбә кыегында сыерчык оясы бар иде. Чичитүш белән Чичиҗан ахырдан аны да ашамакчылар иде, ләкин оя сыерчыклары белән бергә очып китәргә өлгерде. Тычканнар сыерчык оясын ашый алмый калуларына үкенеп торган бер мәлдә, аларны Татлымыр исемле мәче күреп алды. Күреп тә алды, тотынды боларны куарга, тотынды куарга. Тычканнарны бәлки куып та җиткән булыр иде ул, әмма – ни кызганыч! – ошбу урында әкият бетеп китте.

Алла АЙСИНА

Бу сандагы язмаларны Ләбиб Леров әзерләде һәм Г.- Х. Андерсен, Д.Родари, португал халык әкиятләрен тәрҗемә кылды.

Сәләват күпере

5(99) - 1998

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМАТ ҺӘМ МАТБУГАТ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ 1990 елның март аеннан бирле чыга

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства информации и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке.
Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары - җаваплы сәркатип
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Светлана ЯРКОВА рәсемнәре

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 28.04.98 ел.
Басарга кул куелды 28.04.98 ел.
Кәгазь форматы 84x108 1/16.
Басма табак 1,5 (2,1).
Офсет ысулы белән басылда.
Тиражы 19400 данә. Заказ Я-214.
Бәясе килешү буенча.

POINT

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

